وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا

Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез!

6+

# Дин вә Мәгыйшәт

№6 (175). 8 февраль 2013 / 27-рабыгыль-әүвәл-1434

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ





Татарстанда хәнәфи мәзһәбен торгызу

▷2◁





Тәгълим-тәрбия системасында Коръәннең роле

▷3◁





Ярдәм итик!

▷4◁


# 2013 ел Шиһабетдин Мәрҗани елы дип игълан ителде

**Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте 2013 елны Шиһабетдин Мәрҗани елы дип игълан итте. Агымдагы елның гыйнвар аенда мәшһүр дин әһеле, фәлсәфәче, тарихчы, мөгаллим, археолог, этнограф, шәркыять һәм исламият белгече Шиһабетдин Мәрҗанининең тууына 195 ел тулды.**

Шиһабетдин Мәрҗани елын уздыруның төп максаты - мөхтәрәм гыйлем иясе Шиһабетдин хәзрәт, аның чордашлары, фикердәшләре эшчәнлеген өйрәнүгә игътибар юнәлтү, халкыбызның рухи мирасын барлау һәм рухи кыйммәтләрне пропагандалау.

Әлеге ел кысаларында имамнар, галимнәр, зыялылар белән берлектә Мәрҗани чоры казанышларын күзаллау, татар дин әһелләренең дини, фәлсәфи, тарихи хезмәтләрен өйрәнү һәм аны киң җәмәгатьчелеккә таныту бурычы тора.

Әлеге максат һәм бурычларны тормышка ашыру ниятеннән нәзарәт тарафыннан дини-фәнни конференцияләр, бәйгеләр, "түгәрәк өстәл"ләр үткәреләчәк, китаплар нәшер ителәчәк.

Белешмә.

Шиһабетдин Мәрҗани 1818 елның 16 гыйнварында Казан өязе Ябынчы авылында-



гы (хәзерге Әтнә районы) руханилар гаиләсендә дөньяга килә. Аның бабасы Габделкотдус Мәрҗән авылы кешесе була. Шиһабетдин соңыннан бу авыл исемен үзенә псевдоним итеп ала. Әтисе Баһаветдин әл-Мәрҗани заманы өчен алдынгы карашлы һәм төпле белемле шәхес була.

Шиһабетдин Мәрҗани ун ел укып, әтисе мәдрәсәсен тәмамлый, Ташкичү мәдрәсәсендә укыта. 1838 елда Бохарага барып төрле мәдрәсәләрдә гыйлем җыя. 1843 елда Сәмаркандта "Шердар" мәдрәсәсендә укый. Ике елдан Бохарага яңадан әйләнеп кайта һәм данлыклы "Мир гарәп" мәдрәсәсендә гыйлем туплый.

1848 елда Ш.Мәрҗани туган якларына әйләнеп кайта. 1850 елда Казанда беренче Җәмигъ мәчете имамы, 1867 елда Казан мөхтәсибе итеп билгеләнә. 1876-1884 елларда ул Казан татар укытучылар мәктәбендә укыта. Шул ук вакытта Казан университетының археология, тарих, этнография җәмгыяте әгъзасы була, бу оешмада актив эшчәнлек алып бара.

Күпкырлы шәхес буларак танылу алган Ш.Мәрҗанинең утыздан артык хезмәте бар. Әлеге хезмәтләр татар халкы тарихын өйрәнү өчен нигез булып тора. Ул үзенең дини һәм фәлсәфи хезмәтләрендә мәгърифәтчелек, дини-реформаторлык идеяләрен яктырта. Шиһабетдин хәзрәт гомере буе дини-мөгаллимлек һәм гыйльми-тикшеренү эшләрен бергә үреп бара.

"Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар (Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр)" - Мәрҗанинең төп гыйльми хезмәте. Анда татар халкының этник тарихы, мәгарифе, рухи мирасы, күренекле шәхесләре, мәчет-мәдрәсәләре хакында мәгълүматлар тупланган.

Шиһабетдин Мәрҗани 1889 елның 15 апрелендә 71 яшендә Казанда вафат була. Хәзрәт Казанның Яңа бистә зиратына җирләнгән.

# Быел хаҗ программасы 138 мең сум торачак һәм ул барысын да үз эченә ала

**5 февраль көнне Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтендә хаҗ кылуга багышланган утырыш үткәрелде. Анда имам-мөхтәсибләр һәм хаҗ сәфәрен оештыручылар катнашты.**

Утырышта Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте рәисенең беренче урынбасары Габдулла хәзрәт Әдһәмов үткән елда нәзарәт тарафыннан хаҗ сәфәренең уңышлы оештырылуын билгеләп үтте. Мөфтиятнең халыкара элемтәләр бүлеге җитәкчесе Хәбибулла хәзрәт Нәфисуллин "ДУМ РТ Хадж" программасының 2012 елдагы эшчәнлегенә гомуми нәтиҗәләр ясады. "Узган ел алдыбызга куелган бурычлар үтәлде, ниятләнгән барча максатларга ирешелде, Аллага шөкер. Иң мөһиме - барча хаҗиларыбыз хаҗ гыйбадәтен вакытында, җиренә җиткереп үтәде һәм аларның барысы да өйләренә исән-сау әйләнеп кайтты", - диде Х.Нәфисуллин. Аннары ул мөхтәсибләргә 2013 елда хаҗ кылу программасын тәкъдим итте.

2013 елгы программа илебездәге Хаҗ советы стандартларына туры килүе һәм ышанычлы булуы белән аерылып тора; ул үз эченә барлык мөһим булган хезмәт күрсәтүләрне дә ала.

Быелгы хаҗ программасына Казан - Җиддә һәм Мәдинә - Казан һава юлы буенча очу, өзлексез медицина ярдәме һәм медицина иминиятләштерүе, кунакханәдән Әл-Харам мәчетенә намаз укырга бару өчен транспорт белән тәэмин итү, Согуд Гарәбстанында транспорт һәм биш литр зәм-зәм суы белән тәэмин итү, хаҗилар өчен махсус комплект (китаплар, сумка, намазлык), ике тапкыр ашату, корбан чалу йоласын үтәү һәм ихрам (хаҗ киеме) бирү кертелгән.

Сәфәр озынлыгы 19-25 көннән гыйбарәт. Мәдинәдә булу вакыты - 3-8 көн; һәр бүлмәгә 5-8 кешене урнаштыру көтелә; һәр номерда юыну урыны, әл-Харам мәчетеннән 3,5 чакрым ераклыкта урнашу, һәр төркемгә җитәкче билгеләү дә каралган.

Хаҗга очкычлар Казаннан 2013 елның 1-8 октябрендә очар дип көтелә. Хаҗилар якынча 19 октябрь - 10 ноябрь көннәрендә өйләренә кире әйләнеп кайтып җитәчәк.

Хәбибулла хәзрәт Нәфисуллин яңа программаны тәкъдим иткәндә: "Быел хаҗ программасы 138 мең сум тора һәм аңа барысы да кертелгән. Быел ике тапкыр ашату, корбан чалу, ир-атлар өчен ихрам да каралган. Моннан тыш, хаҗиларның барысына да бертөсле багаж сумкалары әзерлибез. Аларга әйберләрен менә шушы юл сумкаларына тутырырга кирәк булачак. Бу - беренчедән, сумкаларның авырлыгы таможня рөхсәт иткәннән артып китмәсен өчен, икенчедән, аларны югалудан саклау һәм, югалган очракта, табуы җиңелрәк булсын дигән максаттан эшләнә", - диде.

Утырышта мөхтәсибләр хаҗны оештыручыларга үзләренең сорауларын, тәкъдимнәрен дә җиткерде. Нәзарәт тарафыннан алар хаҗга кагылышлы мәгълүматлар язылган буклетлар да алды.

Хаҗга кагылышлы өстәмә мәгълүматларны www.dumrt-haj.ru сайтыннан алырга мөмкин.

# Динебездә бала тәрбияләүнең әһәмияте

**Коръән аятьләрендә һәм Пәйгамбәребезнең (сгв) хәдисләрендә тәрбиячеләрнең вазифалары күрсәтелгән һәм тиешлесен үтәмәүләре өчен кисәтүләр ясалган. Балаларны тәрбияләү ул - олы әманәт. Һәм аның җаваплылыгы бик зур.**

Аллаһы Тәгалә "Та-ha" сүрәсенең 132 нче аятендә болай ди: "Әй, Мөхәммәд галәйһиссәлам! Йорт әһелләреңә вә өммәтеңә намаз укуны боер, намаз уку, намазга өйрәтү һәм намазга боеру мәшәкатьләренә сабыр ит".

Аллаһы Тәгалә "Тәхрим" сүрәсенең 6 нчы аятендә әйтә: "Әй, иман китерүчеләр, үзегезне дә, йорт әһелләрегезне дә җәһәннәм утыннан саклагыз". Ягъни, үзегез шәригать хөкемнәрен дөрес үтәп, җәмәгатьләрегезгә дә шәригать хөкемнәрен дөрес өйрәтегез. Һәм бу - Аллаһ Тәгалә боерган фарыз эшләрдән булып тора.

Аллаһы Тәгалә "Нәхел" сүрәсенең 93 нче аятендә: "... Кылган эшләрегездән, әлбәттә, соралырсыз, сакланып эш кылыгыз", - ди. Гаилә кору, балалар үстерү, аларны тәрбияләү, яхшылыкка яки яманлыкка гадәтләндерү бәндәнең кылган гамәлләреннән санала һәм алар турында Кыямәт көнендә соралачак.

Аллаһы Тәгалә "Ән-Ниса (Хатыннар)" сүрәсенең 11 нче аятендә болай ди: "Балаларыгызның хаклары турында Аллаһ сезгә гаделлек кылуны фарыз итте".

Аллаһы Тәгалә "Бәкара (Сыер)" сүрәсенең 233 нче аятендә: "Аналары балаларын тулы ике ел имезерләр", - ди. Бу аятьтә Аллаһы Тәгалә аналарга сабый балаларын имезүне боера.

Аллаһы Тәгалә "Мүмтәхинә (Хатын-кызны сынау)" сүрәсенең 12 нче аятендә: "Һәм үтермәскә сабыйларын", - диде. Ягъни Аллаһы Тәгалә мөэминә хатыннарны балаларын үтерүдән, корсак төшерүдән тыя.

Шулай итеп, бик күп аятьләрдә Аллаһы Тәгалә гаиләне һәм балаларны карарга, тәрбияләргә боерды, бу эшләрдә булган җаваплылык турында кисәтте.



# ТАТАРСТАНДА ХӘНӘФИ МӘЗҺӘБЕН ТОРГЫЗУ



**Исламның хәнәфилек мәгънәсе дигән вакытта, сөнни исламның хокукый бер мәзһәбе генә түгел, ә аның идеологик юнәлеше, ягъни сөнни илаһиятнең мәгънәсе дә күз алдында тотыла. Сүзебезне Идел-Уралдагы беренче ислам җәмгыятьләре хәзәр чорына туры килүеннән башлап китик.**

Тарих, инде VIII гасырда ук Хәзәр империясендә, Түбән Идел төбәгендә мөстәкыйль мөселман җәмгыятьләре булуы, ә Урта Идел болгарларының хәзәрләрнең вассаллары булулары турында дәлилли. Гарәп сәяхәтчесе Әбу Хәмид әл-Гарнатыйның XII гасырда теркәп калдырган болгар риваятендә сөйләнгәнчә, болгарларның бер өлешенең ислам кабул итүе, нәкъ менә шул вакытка фаразлана булса кирәк. Мөселман җирләрендә имам Әбу Хәнифә мәзһәбе таралыш алу вакыты VIII гасыр ахырына туры килә, бу вакытта хәнәфи мәзһәбе галимнәре габбасилар элитасына кергән була. 922 елда бар болгарлар да рәсми рәвештә ислам кабул итәләр, бу вакытта аларның хәнәфи мәзһәбе тарафдарлары булулары турында беренче төгәл искә алулар күренә, андый төгәллек шул елны Болгарда булган Багдад илчелеге сәркатибе Ибне Фадлан отчётында да бар. Ибне Фадлан Болгарны шактый җентекләп тасвир иткән, анда мәчет, мәдрәсәләр булуы, өйлә вакытында җәмәгать намазына чакыру (азан) яңгыравы турында язган. Әлеге язмаларга нигезләнеп, болгар мөселманнарының мәзһәбе турында фикер йөртергә мөмкин. Ибне Фазлан үзе, ул вакыттагы хәлифәнең үзе кебек үк, шәфигый мәзһәбеннән булган, шуңа да ул болгарларны дини гамәлне үз сарайларындагы кебек итеп башкарырга күндерергә тырышкан. Ләкин бу эш барып чыкмаган. Монда финанс факторы да билгеле бер роль уйнаган, чөнки Болгар ханына тәгаенләнгән, Урта Азиядән алынырга тиешле булган акча, хәлифәнең фәрманына да карамастан, барыбер алынмый калган. Илчелекнең сәркатибе болгарларны, аның көенүенчә, "тиешенчә" гыйбадәт кылырга күндерә алмаган. Акчалар, хан казнасы өчен түгел, ә хәзәрләрнең һөҗүмнәренә каршы кирмән төзүгә фатиха бирү өчен генә кирәк булганнар, монда әллә нинди зур матди файда күз алдында тотылмаган. Ханның исә (аның рухи теләге-омтылышы башкарылмавы сәбәпле) күңеле кайткан, ә диндар кеше өчен, билгеле, бу зур әһәмияткә ия һәм шуның нәтиҗәсендә Багдад илчесенең абруе төшкән. Шулай да болгар ханының һәм болгарларның үзләренең кунакчыллыгы һәм башка карашларга түземлегенә (толерантлыгына) тиешле бәя бирергә кирәк. Килеп чыккан бәхәс һәм шау-шудан (скандалдан) соң, ул, мәсьәлә чишелешенең ике як өчен дә уңай (компромисс) вариантын тәкъдим иткән. Берьюлы, бер үк вакытта, ике мөәзин азан әйтә башлаганнар, берсе - хәнәфи мәзһәбе кагыйдәләре, ә икенчесе шәфигый мәзһәбе буенча. Шулай итеп, X гасырда ук инде болгарлар үзләрен хәнәфи мәзһәбенә хас традицияләрне эзлекле яклаучы итеп күрсәткәннәр.

Татарларның күп гасырлар буе хәнәфи мәзһәбенең ныклы тарафдарлары булулары турында инде күп фәнни мәкаләләрдә язылды. (Карагыз: Шәһабиев Д.А. Идел-Урал төбәге мөселманнарының исламның хәнәфи мәзһәбе тарафдарлары булулары турында: тарих һәм хәзерге заман (рус телендә) // Минбар. Выпуск № 2. - 2008. - С. 101-109.) Минем бу урында бер генә мисал китереп узасым килә. Шиһабетдин Мәрҗанинең вәгазьләр җыентыгында никах укуның хәнәфи мәзһәбе үрнәгендә бәян ителгән вәгазь урын алган, ул татарларның аңа кадәр килеп киткән буынында кулланылган. Гарәп хөтбәсеннән (хөтбәт ән-никах) соң ук, авыл мулласы татар телендә: "Шулай итеп, Аллаһы Тәгалә боерыгы белән, Пәйгамбәребезнең (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) Сөннәте белән, Әбу Хәнифә Ногман ибне Сабит әл-Куфи әс-Суфи мәзһәбе буенча..." - дип әйтергә тиеш булган. Традицион хәнәфиләр аның исемен нәкъ менә шулай, суфичылыкка нисбәт итеп, "әс-Суфи" дип әйткәннәр, бу аның суфи булуын аңлаткан. Ә Әбу Хәнифәне исә вафатына кадәр ике ел кала суфичылык юлына баскан дип исәплиләр. Бу турыда хәнәфиләрдәге (Аллаһ аларга хәерхаһлы булса иде!) абруйлы чыганаклар бар мөҗтәһидләрнең дә никах вакытында шиксез әйтелергә тиешле: "Сез, фәлән-фәлән кеше, үзегезнең фәлән-фәлән кызыгызны фәлән-фәлән шул кешегә шундый мәһәр исәбенә кияүгә бирергә ризамы?" - дигән сүзләр булуы турындагы бердәм фикерләр (Кара: Җәмигыль-хотабдан кирәкле хөтбәләр. - Казан: Бертуган Кәримовлар, 1912) дә сөйли. Ягъни, татар мулласы, бу очракта, сөнниләрнең хәнәфи мәзһәбе тарафдары булуны билгеле бер рәвештә шәрехләп китә торган булган.



Татар тарихының күп битләре халкыбызның имам Әбу Хәнифә мәзһәбенең ныклы тарафдарлары булулары турында дәлилли. Кызганыч, XX гасырда үз рухи мирасыбыздан күп елларга сузылган аерылып тору нәтиҗәсендә, Идел-Урал төбәге мөселманнары үзләренең рухи чишмәләреннән, шул исәптән үзләренең рухи хәнәфи чишмәләреннннән дә ераклаштылар. Шуның нәтиҗәсендә, узган гасырның 90 нчы елларында мөселман җәмгыятьләренә, үткән белән бәйләнешне өзгән, ата-бабаларының бөек рухи мирасы белән таныш булмаган, ислам турында белемнәре сай булу сәбәпле акны карадан аера белмәгән кешеләр килде. Алар яхшы ук финансланган идеологик интервенциягә (басымга. - ред.) каршы тора алмадылар. Чит илләрдәге "безгә яхшылык теләүчеләр" безнең мөселманнарның наданлыклары һәм вакытлыча ни эшләргә белми аптырап калуларыннан оста файдаландылар, аларга безнең өчен традицион (гадәти. - ред.) булмаган исламның үз мәзһәбләрендә ялгыш аңланган тәгълиматларын сеңдереп, таратып калырга тырыштылар. Моңа каршы торучы һәм андый интервенцияләргә (һөҗүмнәргә. - ред.) каршы чыгыш ясаучылар берничә генә кеше булды. Мәсәлән, безнең инде мәрхүм булган мөгтәбәр зат - Габделхак хәзрәт Саматов һәм 2012 елның рамазан ае алдыннан шәһит киткән Вәлиулла хәзрәт Якупов шулар исәбендә. Без бүгенге көндә кайбер җирле мөселманнарның күпгасырлык дини мирасыбыздан ваз кичүләренә, элеккеге хәнәфи мәзһәбе галимнәренең абруйларын танымауларына шаһитбыз. Ә соңгы буын хәнәфи мәзһәбе галимнәренең өйрәтүләре турында әйтәсе дә юк. Без, хәзерге вакытта, мөселман яшьләре арасында гына түгел, ә хөрмәткә лаек өлкән буын дин әһелләребез арасында да үзләренчә сәләфиләр дип аталучыларның ислам дөньясын глобальләштерүне хуплау пропагандасы нәтиҗәләрен күрә алабыз. Алар авызыннан кайвакыт шундый сүзләр дә ишетергә туры килә: "Без фикъһе мәсьәләләре буенча хәнәфи мәзһәбендә торабыз, ә гакыйдәдә сәләфилар мәзһәбендә". Мөселман яшьләренең ата-бабалар мәзһәбе буенча баруларын теләмәгәннәрен күрер өчен, бүгенге көндә мәчет һәм кайбер мәдрәсәләрне урап чыгу да җитә. Бу яшьләрдән ишетергә туры килгәннәр арасында иң яманы шул: алар мәзһәбне Пәйгамбәребезнең (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) Сөннәтенә каршы куялар; алар әйтүенчә, үзләре, имеш, Мөхәммәд пәйгамбәр (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) өйрәтүләре буенча баралар, башкалар исә - Әбу Хәнифә өйрәтүләре буенча. Кызганыч, шул дәрәҗәдәге наданлык та күзәтелә.

XX йөзнең 90 нчы елларындагы дини сәясәтнең тискәре нәтиҗәләренә дә карамастан, хәнәфи мәзһәбе тарафдарлыгы бездә, акрынлап булса да, торгызыла бара. Шул вакытлардан ук вазгыятьтәге бу кытыршылыкларны бетерү юлында тырышкан кайбер дин эшлеклеләре һәм оешмаларны әйтеп китәргә кирәк. 1993 елда Казанда "Мөхәммәдия" мәдрәсәсе үзенең ишекләрен янә ачты. Бу - коммунистлар чорыннан соң Идел буенда ачылган беренче дини югары уку йорты булды. Аның оештыручысы - "Иман" ислам мәдәнияте үзәге булды (башта аны ислам институты дип атап йөрттеләр). Оештыручылар фикеренчә, бу мәдрәсә инкыйлабка чорына кадәрге Казандагы "Мөхәммәдия" (1882-1917) мәдрәсәсенең традицияләренең дәвамчысы булырга тиеш иде. "Мөхәммәдия" мәдрәсәсе - үз заманында мөселман татарлар өчен югары уку йорты булган. 1993 елның 1 октябреннән бу уку йортында регуляр рәвештә төрле ислам дисциплиналарын укыта башлыйлар. Мәдрәсәнең беренче елларында биредә фикъһене Сабикъның "Фикъһе әс-Сөннә"се буенча укыталар. Бу дәреслек төрле мәзһәб хөкемнәрен берләштерергә, катнаштырырга (тәлфикъ - авт.) мөмкинлек бирә һәм, хәтта, кануни дүрт мәзһәбнең берсе тарафдары булуның үзен үк инкяр да итә. Бу китапны файдалану - безгә килгән гарәп мөдәррисләре һәм хәйриячелек белән бәйле була. Мәдрәсә җитәкчелеге, мәсьәләнең әһәмиятлелеген аңлап, программага параллель рәвештә фикъһенең хәнәфи мәзһәбе буенча да дәресләр кертә. Бу дәресләрне мөхтәрәм Габделхак хәзрәт Саматов алып бара, ул бу вакытта Мәрҗани мәчетенең имамы булып эшләгән була. Бәлки, шуңадыр да, мәдрәсәнең беренче агымдагы шәкертләре хәнәфи мәзһәбе тарафдарлары булып киткәннәрдер дә. (Кара: "Мөхәммәдия" мәдрәсәсе: традицияләрнең дәвам ителүе (рус телендә). - Казань: ДУМ РТ, 2008. - С. 144-145.) Ул вакытлардан соң вазгыять бик нык үзгәрде. Хәзерге вакытта мәдрәсәләрдә хәнәфи мәзһәбенең илаһият-дини дәреслекләренә өстенлек бирелә, чөнки мөселман татарларда исламның нәкъ менә илаһият белгечләренә ихтыяҗ бар. Хәзер, соңгы елларда, шәкертләр фикъһене хәнәфи чыганагы булган "Әл-Ихтияр" дәреслеге буенча өйрәнәләр.

Башка мәдрәсәләрдәге кебек үк, бу мәдрәсәдә дә җитәкчелекне ислам тәгълиматын - гакыйдәне укыту мәсьәләсе борчый. "Мөхәммәдия" Казан югары мөселман мәдрәсәсендә, шулай ук 1998 елда ачылган Россия ислам университетында да әүвәлге дәвердә исламның "ваһһаби" аңлавын укыткан булалар. Бу - гакыйдәне Согуд Гарәбстанында эшләнгән программалар буенча укытылуга бәйле була, һәм шуңа да, бу студентлар, иртәме-соңмы, өлкән яшьтәге дин әһелләре һәм мәчеткә йөрүчеләр белән каршылыкка киләчәкләр иде. "Мөхәммәдия"дә һәм РИУда бераз вакыт гакыйдәне "Шәрех әл-гакыйдә әт-тәхавиййа" дәреслеге, төгәлрәк итеп әйткәндә, аның җиңеләйтелгән варианты "Тәхзиб шәрех әт-тәхавиййа" буенча укыттылар. Ул, нигездә, тулысынча хәнәфи тәгълиматына туры килергә тиеш иде. Иман символы авторы әт-Тәхави - башлангыч хәнәфилекнең билгеле авторитеты. Ләкин бу китап Ибне Әбу-л-Гыйз әл-Азрагый аңлатуының кыскача варианты булып чыкты. Имам ибне Әбу-л-Гыйз әл-Азрагый хәнәфи фикъһе тарафдары булса да, гакыйдәдә каты сәләфилек юнәлешендә булган, ягъни Ибне Таймия идеяләре тарафдары. Бу китапның икенче кыскартылган һәм җиңеләйтелгән варианты авторы Габд әр-Рахман әл-Хөмәййис, үзенең кереш сүз өлешендә, аңлатучы әт-Тәхави сүзләрен өч урында төзәткән дип язган (Әл-Хөмәййис, М.Габд әр-Рахман. Шәрхе гакыйдә әт-тәхавиййа әл-мүйәссәр. - Әр-Рияд: Дар әл-ватан, елы юк. Б. 6), аның буенча аңлатучының карашлары турында фикер йөртергә була. Бу вариант Татарстанда бушлай таратылды. Алда искә алынган Мөхәммәд әс-Сави төзегән беренче вариант та, гарәп илләренең хәйрия акчаларына махсус нәшер ителгән һәм таратылган, шуның өстәвенә, - татарчага да тәрҗемә ителгән. Шуңа күрә, Согуд Гарәбстаны галимнәре уку дәреслеге итеп тәкъдим иткән бу китап - укыту кулланмасы булып безнең төбәктә файдаланыла алмый. Чишелмәгән мәсьәлә, иң беренче, ысул әд-дин яки гакыйдә өлкәсендә махсус белемле, традицион юнәлешле дини уку үзәкләрендә әзерлек үткән мөгаллимнәр булмавында иде. Матуриди гакыйдәсе буенча булган чыганаклар кабаттан нәшер ителмәгән һәм тәрҗемә дә ителмәгәннәр иде. Шулай итеп, без хәнәфи туны ябынган "сәләфиләр" феномены белән очраштык, ягъни хәзерге вакытта тышкы яктан хәнәфи мәзһәбе тарафдары булып күренсәләр дә, дин тәгълиматын үзләренең аңлауларында Әбу Хәнифә гакыйдәсенең кайбер мәсьәләләрендә хаклы булмаган, матуридилар исә, чын "сәләфи" гакыйдәсеннән гомумән читләшкәннәр дип исәпләгән мөселманнар да бар.

Хәнәфи мәзһәбендәге исламны, аның фикъһе мәгънәсендә дә, гакыйдә мәгънәсендә дә кире торгызуда төп, аеруча әһәмиятле юнәлешне хәзерге вакытта Казандагы Россия ислам дарелфөнүне башкара. Монда соңгы ике дистә елда мөселман җәмгыятендә барлыкка килгән тискәре күренешләрне бетерү өстендә максатчан эш алып барыла. Гакыйдәне укыту бүгенге көндә иманның ике символы нигезендә хәнәфи имамнары әт-Тәхави һәм ән-Нәсәфи өйрәтүләре буенча алып барыла һәм нәкъ менә хәнәфи галимнәре аңлатуының тулы мәгънәсендә файдаланыла. Нәсәфи иман символының Гыйрак дин галиме Габд әл-Малик әс-Сәгъдинең аңлатмалары рус теленә тәрҗемә ителде. Әл-Гонәйми әл-Мәйданиның тәхави кредосына хәнифи аңлатулары, Нур әд-дин әс-Сабунининың "әл-Бидайа фи ысул әд-дин" китабы һәм матуриди мәзһәбенең билгеле чыганагы тәрҗемә ителә башлады. Тарих фәннәре кандидаты, РИУның ислам тәгълиматы кафедрасы доценты Габдулла хәзрәт Әдһәмов хәнәфи китаплары нигезендә мөселман тәгълиматы буенча дәреслек әзерләде. Аннан тыш, студентлар өчен ислам тәгълиматы буенча ике хрестоматия дә төзелде. Анда башлангыч һәм соңгы дәверләрдәге сөнни галимнәрнең гакыйдә буенча текстларының русчага тәрҗемәләре тупланган. Инде ике тапкыр, 2008 нче һәм 2010 нчы елларда РИУ мөгаллиме Рөстәм хәзрәт Нургалиев әзерләгән "Әбу Хәнифә мәзһәбе буенча намаз уку" дип аталган брошюра басылып чыкты.

РИУ җитәкчелеге һәм укытучылар студентларны ата-бабаларыбызның дини мирасына, шул исәптән хәнәфи авторлары хезмәтләренә ныклы инану җирлегендә сак карарга төрле яктан ярдәм итәләр.

**Сәет-Дамир ШӘҺАБИЕВ,**
**тарих фәннәре кандидаты,**
**Татарстан Фәннәр академиясенең Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институтының иҗтимагый фикер тарихы һәм исламны өйрәнү бүлеге мөдире**

# Тәгълим-тәрбия системасында Коръәннең роле

**Халкыбызның үткәндәге тарихында, яшәешендә, мәдәниятендә һәм рухи тормышында тирән эз калдырган вакыйгалар шактый. Алар арасында ислам дине белән бәйләнештә булганнары да бар. Шуларның берсе - 922 елда Идел Болгарстаны дәүләтендә рәсми рәвештә ислам динен кабул итү.**

Исламны кабул иткән болгарларда шул дәверләрдән алып җәмгыять тормышының барлык өлкәләрендә тирән үзгәрешләр башлана, халыкның тәрбия тәҗрибәсе яңа әхлакый кыйммәтләр белән байый, яңа эчтәлек ала, тәрбия тәэсире яңарыш кичерә. Чөнки кешеләрнең рухи-әхлакый ихтыяҗларын канәгатьләндерү ислам диненең иң әһәмиятле вазифасы булып тора. Ул гаделлек, шәфкатьлелек, кешелеклелек, сафлык, сабырлык, үз хезмәте белән гадел көн күрү идеалларын яклый һәм аларны шәхесне формалаштыруда фарыз гамәлләр дип исәпли. Алар халкыбызның уй-фикерләрен, дөньяга карашын һәм яшәеш кануннарын изгеләштерә, нәтиҗәдә, инсаннарны яман адымнар, хәрам эшләр кылудан саклап кила. Шул ук вакытта Болгарда ислам дине кабул ителгәннән соң, элек-электән яшәп килгән мәҗүси гореф-гадәтләрдән, йолалардан, хорафатлардан, тискәре күренешләрдән арыну процессы башлана. Халкыбыз тарафыннан гасырлар дәвамында укылып килгән "Бәдәвам китабы" да әнә шундый ышануларга каршы үзенчәлекле өндәмә булып яңгырый:

***Һәркем җенгә табынса,***
***Йә суга нәрсә салса,***
***Агачка нәрсә чалса,***
***Аллаһ дигел бәдәвам.***

Һәр строфаның соңгы юлы "Аллаһ дигел бәдәвам" дип тәмамлана, ягъни һәрдаим Аллаһ сүзен кабатларга кушыла.

Дини, фәлсәфи, идеологик, хокукый һәм әхлакый система буларак, ислам диненең халкыбыз тормышы тарихындагы мөһим роле әхлакый концепцияләр белән генә чикләнми. Ул, беренче нәүбәттә, татар халкын туплауда, төрле кавемнәрне берләштерүдә, болгарларның дәүләт булып оешуына уңай йогынты ясый. Шул дәүләтнең идеологик асылын тәшкил итә. Икенчедән, ислам дине үз чорында шактый үсештә булган гарәп-мөселман мәдәниятенең йогынтысын көчәйтә. Болгар халкы гарәпләрдән кергән фәнни-фәлсәфи идеяләр, бай әдәби мирас белән танышу мөмкинлеге ала. Өченчедән, бабаларыбыз тарафыннан кулланылган рун язуы гарәп әлифбасы белән алышына, шул рәвешле меңьеллык язма мираска нигез салына. Шулай итеп, ислам динен кабул итү яңа фәнни-фәлсәфи фикерләр таралуга, мәдәният һәм мәгърифәт үсешенә куәтле этәргеч була. Тәгълим-тәрбия өлкәсендә билгеле бер система барлыкка килә. Мәктәп-мәдрәсәләрдә, дин сабагыннан тыш, дөньяви белемнәр бирүгә дә зур урын бирелә. Бу система Алтын Урда һәм Казан ханлыгы чорында да, Рус дәүләте тарафыннан яулап алынгач та сакланып кала. Нәтиҗәдә, халкыбызда мәгърифәт, уку-укыту һәм тәрбия эшенең сизелерлек үсүе, шул нигездә болгар-татарлар арасында белемлелекнең шактый югары дәрәҗәдә булуы күзәтелә.

Болгарларда ислам кабул итүнең тагын бер мөһим иҗтимагый-тарихи әһәмиятен күрсәтергә кирәк. Ул халкыбызның милләт, этник берәмлек булып сакланып калуын тәэмин итә. Мәгълүм булганча, болгар-татарларга XIII йөзләрдән үк башланып киткән төрле җәбер-золымнар кичерергә туры килә. Шундый авыр дәверләрдә дә ул үзен кавем-халык буларак сакланып кала ала һәм монда, һичшиксез, гаять көчле берләштерүче үзәк буларак, динебез хәлиткеч роль уйный. Шуның нәтиҗәсендә халкыбыз үзенең күркәм традицияләрен, гореф-гадәтләрен, бай мәдәниятен, телен, милли үзенчәлекләрен саклап кала һәм алга таба үстерә ала. Патша хакимияте һәм миссионерлар басымы чорында да халкыбызның бердәмлеген һәм бербөтенлеген, аның милли асылын саклауда ислам дине төп идеологик терәк була, мөселман мәктәп-мәдрәсәләрендә милли үзаң формалаштыруда, дини-әхлакый тәрбия бирүдә дә ныклы нигез булып тора.



Гомумән, ул заманнарда ислам дине мөселман кешесенең рухи терәге генә түгел, ә аның яшәү рәвешенә әверелә, татар кешесенең барлык тормыш-көнкүреше шәригать кануннары буенча тәртипкә салына.

Исламда дингә ихтыярсыз буйсындыру юк, ә дингә өндәү, вәгазьләү генә бар. Аның нигезен исә, Коръән-Кәрим алып тора.

Коръән (гарәпчәдән "яттан уку, яттан сөйләү") Ислам фәлсәфәсендә Изге Китап булып санала. Илаһият фәнендә аның 55 атамасы бар дип күрсәтелә: Коръән-Кәрим (кәрим-хөрмәтле, кадерле, бөек, газиз); Коръән-Мәҗид (мәҗиддanлы, мактаулы); Коръән-Газим (газим - алдан уйлап куючы, исәпләүче, ниятләүче; батырчылык итүче; кыюлык итүче; баручы, юл тотучы); Китабуль-зекер (зекер-искә алучы, искә төшерүче); Китабуль-мөбин (мөбин-дөреслек белән ялганны аеручы); Өммелкитап (Китаплар анасы); Форкан (Коръән); Кәлямулла (Аллаһ сүзе, Коръән); Мосхәф шәриф (кадерле Коръән) һ. б.

Коръәннең үзәгендә бер Аллаһка ышану-инану идеясе ята. Ул барысын да яратучы, тиңсез, кодрәтле. Коръәни-Кәримдә Аллаһы Тәгаләнең 99 исеме һәм асыл сыйфатлары булуы турында әйтелә. Изге Китапта ислам диненең асылы, шәригать кануннары, Адәм галәйһиссәлам балаларының яшәү рәвешләре аңлатыла. Алар арасында аеруча мөһим булганнары түбәндәгеләр: Алаһы Тәгаләнең берлегенә һәм барлыгына, Мөхәммәд пәйгамбәрнең (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) Аның илчесе икәнлегенә ышану ("Лә иләһә илләллаһү Мөхәммәдү рәсүлүллаһү"), биш вакыт намаз (ас-саләт), Рамазан аенда ураза тоту (ас-саум), мохтаҗларга өлеш чыгару (зәкят) һәм хаҗга бару.

Коръәни-Кәримдә Ислам кануннары һәм фазыйләтләр кешенең фикерләве, рухи халәте, үз-үзен тотышы белән тыгыз бердәмлектә бирелә. Эчтәлеге гаҗәеп бай: Аллаһы Тәгалә һәм Аның асыл сыйфатлары; инандыргыч дәлилләр; мөэмин-мөселманнар һәм мөселман булмаганнар; пәйгамбәрләр һәм халыклар; җиһан турындагы фикерләр; җәмгыять төзелеше; туу, яшәү һәм үлем; гаилә; әдәп-әхлак мәсьәләләре; гыйбрәтләр, хәерле һәм бозык эш-гамәлләр; гыйлем алу һ. б. Анда инсанны бизи торган әхлакый сыйфатларга аеруча зур урын бирелә: тугрылык, гаделлек, ихласлык, юмартлык, шәфкатьлелек, сабырлык, ата-ананы хөрмәтләү, сүз һәм эш-гамәл берлеге һ. б. мактала, ә аларның тискәреләре төрлечә хөкем ителә. Бигрәк тә ялганлау, кеше канын түгү, фетнә тарату, икейөзлелек, эчүчелек, зина кылу, хәрам мал туплау, гайбәт сөйләү һ. б. гаепләнә, алар зур гөнаһлардан санала.

Коръәни-Кәрим конкрет тарихи җирлектә, билгеле бер иҗтимагый-сәяси шартларда барлыкка килгән. Изге Китапта шул дәвер кешеләренең гореф-гадәтләре, мифологик күзаллаулары, фикерләү үзенчәлекләре дә гәүдәләнеш тапкан. Әмма Коръәндә вакытлы, тарихи күренешләрне тасвиралау аша, гомумән, инсаният, җәмгыять, яшәеш хакында фәлсәфи уйланулар бәян ителә.

23 ел дәвамында Җәбраил фәрештә арадашчылыгында Аллаһтан Мөхәммәд пәйгамбәргә (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) иңдерелгән Коръәни-Кәрим 114 сүрәдән (бүлектән) гыйбарәт. Анда алар үзләренең күләмнәренә карап урнаштырылганнар: әүвәл (беренче сүрәдән кала иң озыны, аннан соң кечерәкләре). Сүрәләрнең һәрберсе, эчтәлекләренә һәм нигез мәгънәләренә нисбәтле рәвештә исемләнгән: 1) "Фатиха (Ачучы)" сүрәсе; 2) "Бәкара (Сыер)" сүрәсе; 3) "Әл-Гыймран (Гыймранның гаиләсе)" сүрәсе; 22) "Хаҗ" сүрәсе; 30) "Рум" сүрәсе; 62) "Җомга" сүрәсе; 114) "Нәс (Кешеләр)" сүрәсе.

Һәр сүрә аятьләрдән (тәгъбирләрдән) тора. Аларның да күләмнәре төрлечә. Мәсәлән, 108 нче "Кәүсәр (Байлык)" сүрәсе өч аятьтән, ә иң озыны булган "Бәкара" сүрәсе 286 аятьтән гыйбарәт. Коръәни-Кәримнең төрле басмаларында 6204тән алып 6239га кадәр аять урын алган. (Әхмәдһади Максудиның "Гыйбадәте Исламия" китабында: "Коръәндә барлыгы 6226 аять бар", - диелгән.) Бер аять берничә хәрефтән дә, сүз яки сүзләр тезмәсеннән, җөмләдән яисә берничә җөмләдән дә торырга мөмкин. Коръән гыйлеме галимнәре күрсәткәнчә, бу аятьләрдә 77934-79934 лексик берәмлек бар.

Мөхәммәд пәйгамбәр (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) яшәгән дәвердә (571-632) аның өйрәтмәләре эзлекле рәвештә язып алынмаган, халык арасында телдән таратылган, бары тик кайбер фикерләре генә теркәлеп калган. Рәсүлебезнең (сгв) вафатыннан соң, хәлифә Әбу Бәкер заманында, бу тәгълиматны язып туплауга карар кылынган һәм бу вазифа Зәйд ибне Сабитка тапшырылган. Ул үзе һәм пәйгамбәргә якын башка кешеләр яттан белгән сүрәләрне, аерым урыннарда язылган мәтеннәрне (текстларны) туплап, күчереп язган. Шул рәвешле 632 ел азакларында беренче мәртәбә Коръән мәтене барлыкка килгән. Тарихи чыганакларда ул "Сухуф" (ягъни "сәхифәләр - аерым битләр") дип телгә алына.

Коръән башта кулъязма рәвешендә генә таралган. Бөек хәлифә Госман әмере белән төзелгән "Мосхәф" (651 елда төзелгән җыентык) барлык кулъязмалар өчен нигез чыганак буларак хезмәт иткән. Аннан күчерелгән иң борынгы кулъязмаларның дүртесе безнең көннәргә кадәр килеп җиткән. Алар Мәккә, Каһирә, Вена, Ташкент калаларының иң мәртәбәле урыннарында саклана.

Элек-электән Коръәнне күчереп язу гаять җаваплы һәм саваплы хезмәтләрдән саналган. Моны гыйлемгә, матур язуга (каллиграфиягә) маһир булган осталар-хаттатлар башкарган. Аны күчереп язуның төрки халыкларда, шул исәптән татарларда да ифрат бай тәҗрибәсе булган.

Китап басу эше җайга салынгач та, Шәрекъ илләрендә Коръәни-Кәримне басма рәвештә тарату тыелып киленгән. Аллаһ сүзен басма хәрефләр белән бирү гөнаһ саналган. Аны бары тик кулъязма рәвешендә генә тарату мәгъкуль күрелгән. Әмма бу Изге Китапка булган ихтыяҗны аз санлы кулъязмалар гына канәгатьләндерә алмаган. Акрынлап аны бастырып чыгара башлаганнар. Мөхтәрәм галимебез Ризаэддин Фәхреддин билгеләп үткәнчә, аның гарәпчә басма нөсхәләре 1881 елда Истанбул шәһәрендә нәшер ителгән.

XVIII йөз ахырларында Коръәни-Кәримне бастырып чыгару Россиядә дә башлана. 1787 елда Екатерина Икенченең махсус фәрманы белән Коръәннең гарәпчә тулы тексты дөнья күрә. Аны хәзерләүдә Диния нәзарәте казые Госман хәзрәт Ибраһимов зур эшчәнлек күрсәтә. Бу басма 1789, 1793, 1796 һәм 1798 елларда кабаттан бастырыла. XIX гасыр башында (1801) Ул Казанда да нәшер ителә. Кайбер мәгълүматларга караганда, XIX йөз дәвамында Коръәннең 21 басмасы дөнья күрә. 1892-1899 нчы еллар эчендә генә дә Изге Китап 276 мең данәдә нәшер ителә. Совет хакимияте елларында бу эш, нигездә, туктатыла. 1917-1990 нчы елларда Коръән бары тик 8 мәртәбә генә басылып чыга. Узган гасырның 90 нчы елларыннан соң гына бу изге гамәлият яңадан тормышка ашырыла башлады. Алар арасында үзебездә нәшер ителгәннәре дә, чит мәмләкәтләрдә эшләнгәннәре дә байтак.

**Фәрит МИҢНУЛЛИН,**
**филология фәннәре кандидаты,**
**Татарстан Фәннәр академиясенең**
**Ш.Мәрҗани исемендәге**
**Тарих институтының өлкән фәнни хезмәткәре**

*(Дәвамы киләсе санда.)*

# Төрки-болгар-татарларның экстремизм идеологиясен кисәтү буенча тарихи тәҗрибәсе

*(Ахыры. Башы газетабызның 1 февраль санында.)*

Казан ханлыгы вакытында да әдәби әсәрләр тәрбия бирүнең, педагогиканың нәтиҗәле чарасы булуын дәвам иттерә. Әдәби әсәрләр шулай ук дини, дөньяви һәм фәнни белемнәр таралыш алуның тәэсирле чарасы булып кала. Ул вакытта иҗат ителгән поэмаларның кереш өлешләрендә ислам тарихы бәян ителә. Аларда пәйгамбәрләр, беренче тәкъва хәлифәләр, ислам дөньясының күренекле шәхесләре, астрономия, география, тыйб (медицина) фәннәре турында кыскача мәгълүматлар бирелә. Әлеге әсәрләр бу җәмгыятьтә бар кеше дә яхшы, гаделлек яклы булсын дигән максатны күздә тотып язылган. Гаделлек барыннан да өстен. Мөхәммәдьярның "Нуры содур" ("Күңелләр нуры") поэмасында иң мөһим әхлакый сыйфатлардан рәхим-шәфкатьлелек, юмартлык, тыйнаклык, оялчанлык, гаделлек, эчкерсезлек, тугрылык, батырлык һ. б. күрсәтелә. Болардан башка кешене интеллигент итеп күз алдына китерү мөмкин түгел. Моннан башка бер генә җәмгыять тә яши алмый.

Мөхәммәдьяр югарыда телгә алынган поэма структурасын тулысынча әхлакый һәм педагогик мәсьәләләргә буйсындыра. Поэманың беренче бабы (бүлеге) - гаделлеккә ("гадел кылу"), икенчесе - рәхим-шәфкатьлелеккә ("рәхим-шәфкать"), өченчесе - юмартлыкка ("сәхавәт"), дүртенчесе - оялуга ("хәя"), бишенчесе - газаватка (игелеклелек), алтынчысы - сабырлыкка, җиденчесе - вафага (әйткән сүзеңдә тора белү), сигезенчесе - сыйдыкка (тугры сүзле булу; турылык, чынлык, раслык, дөреслек), тугызынчысы - самитка (аз сүзле булу, телеңне тыя белү), унынчысы - гафу (кичерә) белүгә багышланган.

Әлеге сыйфатлар укучыларга тизрәк барып ирешсен һәм тәэсирлерәк булсын өчен алар поэмада мөселман дөньясына яхшы билгеле булган тарихи образларда күрсәтелә. Ә "Төхфәи мәрдән" ("Егетләргә бүләк") поэмасында кеше сыйфатлары уйлап чыгарылган образларда чагылдырыла: Чынбил (гаделлек, тугрылык, хакыйкатькә ирешү; дөреслекне белүче); Тойгысун (мәкерлелек, комсызлык, гыйсъянчы-фетнәче; ач күз, комсыз кеше); Гөлруй (тышкы матурлык символы; гөл йөзле); Хушхун, Хушнәва (эчке күркәмлек, вөҗдан матурлыгы символы; матур тавышлы); Безбаз (тупаслык, дорфалык, тәкәбберлек символы; лачын). Шулай ук Тәүрат/Коръән образлары, әйтик, Карун (чиксез байлыкка омтылу, комсызлык символы) һ. б. кулланыла.

Төп сыйфат - гаделлек. Калган бар сыйфатлар да гаделлеккә ирешү чаралары гына булып тора. Шулай ук хәя (ояла белү) сыйфаты булу да зарури. Ул иман белән тыгыз бәйләнгән.

Мөхәммәдьяр поэмаларына үгет-нәсыйхәтләр, күрсәтмәләр бирү, зирәк сүзләр әйтү хас. Автор, ораторлык сәнгате сыйфатларын кулланып, укучыларга еш мөрәҗәгать итә, төрле чыганаклардан (шул исәптән фольклордан - афоризмнардан, канатлы сүзләрдән дә) файдалана. Мәкаль-әйтемнәр куллану аеруча еш очрый. Мөхәммәдьяр "Нуры содур" поэмасында ышандыру көчен, тәэсирлелекне арттыру өчен Коръән аятьләрен һәм хәдисләрне нигез итеп ала. "Нуры содур" поэмасының хәягә (ояла белүгә) багышланган дүртенче бүлегендә шагыйрь пәйгамбәребез Мөхәммәд (сгв) хәдисләрен турыдан-туры шигъри юлларга күчереп, тәрҗемә итеп бирә. Ягъни ояла белү, оялчанлык Аллаһка чын күңелдән инанганнарда гына була. Әгәр дә Аллаһы Тәгалә кешегә иман бүләк иткән икән, бу кеше оят дигән нәрсәне гомеренең азагына кадәр саклаячак.

Шулай итеп, болгар-татар җәмгыятьләре һәрбер конкрет кешене акылга сыймаслык адымнардан, шул исәптән экстремистик характердагы гамәлләрдән дә аралап тора торган тулы бер система төзегән булганнар.

**Гамирҗан ДӘҮЛӘТШИН,**
**тарих фәннәре докторы,**
**Казан (Идел буе) федераль университетындагы Тарих институтының төрки халыклар тарихы һәм мәдәнияте кафедрасы профессоры**

## Кадерле дуслар!



**22 яшьлек, шат күңелле яшь кыз сезнең ярдәмегезгә мохтаҗ. Таныш булыгыз - Миләүшә Газизова. Ул Актанышта яши, тыйнак елмаюы белән генә дә тирә-яктагыларны үзенә карата.**

**Миләүшәдә Саркома Юинга авыруы (сөяк миендә яман шеш) тапканнар. Дәвалануның беренче этабы Казанда үтә, ләкин нәтиҗәсез була. Шеш үскәннән-үсә. Хәзер Миләүшәгә чит ил белгечләре генә ярдәм итә ала. Дәвалану якынча 4 миллион сумга төшәчәк. Ул дәвалана торган клиника счёты белән сез Миләүшәнең рәсми төркемендә таныша аласыз: http://vk.com/club48622834.**

**Дүрт миллион сум Россия кешесе өчен зур сумма. Ләкин кешеләргә һәрвакыт кызгану һәм шәфкатьлелек хисе хас. Исәпләп карагыз: 20 мең кеше 200 сум бирсә Миләүшә сәламәтләнә алачак.**

**Кеше хәленә керә алу һәм шәфкатьлелек безне Аллаһы Тәгаләгә якынайта, бу сыйфатлар бездә булмаса, бездә бернәрсә дә юк дияргә була (Иоанн Златоуст).**

**Миләүшә өчен ярдәм кулын сузуы авыр түгел. Сез үзегезгә җайлы теләсә нинди юл белән акча күчерә аласыз (барлык реквизитлар да ВКонтакте сайтындагы төркемдә бирелгән).**

**Сәламәт һәм бәхетле булыгыз!**

**Татфондбанк карточкасы номеры - 4172270007077285**
**Телефон номеры - Билайн: 89093121925**

**Киви кошелёк - +79600608171**
**ЯНДЕКС КОШЕЛЕК - 410011450592629**

## Игътибар!

***2013 елның 16 февралендә иртәнге сигездән (8.00) көндезге икегә (14.00) кадәр Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика кан күчереп салу станциясендә кан тапшырырга теләүчеләрне көтәләр. Станция Казан шәһәре, Себер тракты урамы, 33 нче йорт адресы буенча урнашкан. Кеше гомерен саклап калу өчен кан биреп ярдәм итү безне Аллаһы Тәгаләгә якынайта, бик саваплы эш булып тора.***

***Кан тапшырырга теләгән һәр кеше әлеге игелекле эштә катнаша ала. Белешмәләр өчен телефон: 89872639889 (Гөлнара).***

***P.S. Кан тапшыру өчен үзең белән Россия Федерациясе паспорты һәм Татарстан пропискасы булу шарт.***

***Әлеге мәгълүматны дусларыгыз арасында да таратсагыз, бик тә рәхмәтле булыр идек!***




# Динебездә бала тәрбияләүнең әһәмияте

Пәйгамбәребез (сгв) әйткән:

"Ир кеше үз гаиләсендә көтүче һәм көтүе өчен соралачак, хатын-кыз иренең өендә көтүче һәм көтүе өчен соралачак..." Ягъни ир кеше үзенең гаиләсе өчен соралачак: аларга иман өйрәткәнме, фарызларны үтәүләрен караганмы, яхшылыкка боерган, начарлыктан тыйганмы, хәрам эшләрдән һәм хәрам ризыклардан саклаганмы, изгелекләр кылырга өйрәткәнме һ. б. Ир кеше йорт әһелләренең дөньялыклары өчен генә түгел, ә ахирәт гамәлләре өчен дә җаваплы.

Шулай ук Пәйгамбәребез (сгв) әйтте:

"Ир-атның баласын тәрбияләве бер саг (3,2-4 кило сыешлы савыт) сәдака бирүеннән хәерлерәк". Бу хәдистән исә сәдакалар биреп тә, балаларын тәрбия кылуны оныткан кешегә караганда, балаларын тәртип-әдәпкә өйрәтүченең хәерлерәк икәнлеге аңлашыла. Пәйгамбәребез (сгв) әйткән:

"Балаларыгызга һәм йорт әһелләрегезгә изгелек өйрәтегез һәм аларда әдәплелек тәрбияләгез".

"Балаларыгызда өч сыйфат тәрбияләгез: пәйгамбәрләрне сөю, аның йорт әһелләрен сөю, матур итеп Коръән уку".

Сәхабәләр һәм тәбигыйннәр (сәхабәләргә иярүчеләр) заманында аталар балаларына иң яхшы гыйлемле һәм әдәпле тәрбиячеләрне сайлаганнар.

Гукъбә ибен Әбу Суфьян баласын тәрбиячегә биргәндә әйткән:

"Улыңны төзәтә башлауны и? әүвәл үзеңне төзәтүдән башла, чөнки аларның күзләре синең күзләргә бәйле, син яхшы санаган әйберләр, алар өчен дә яхшы булып күренерләр, син начар санаган әйберләр, алар өчен дә начар булып күренерләр. Аларга хикмәтле кешеләрне? тормыш юлларын һәм әдәпле кешеләрне? әхлакларын өйрәт. Аларны Минем белән куркыт, һәм Мин юкта тәрбиялә (җәза бир). Чирне белми торып, дәва бирми торган табиб кебек бул син аларга..."

Хәлифә Һарун Әр-Рашид үзене? улы Әминне тәрбиячегә тапшырганда әйткән: "... Булдыра алган балалар бакчаларына, мөселман мәктәпләренә биреп, аларны мәчет-мәдрәсәләргә йөртеп, мөселман гаиләләре белән таныштырып булыр иде.

Ата-ана өстендәге тәрбия җаваплылыгын җиде төргә бүлеп карарга мөмкин:

1) иман тәрбияләү;
2) холкын тәрбияләү;
3) тәнен тәрбияләү (ашату, эчертү һ. б.);
4) акылын тәрбияләү (гыйлем өйрәтү һ. б.);
5) җанын тәрбияләү;
6) җәмгыяви яктан тәрбияләү (җәмгыяттә үзен тотарга өйрәтү һ. б.);
7) женси тәрбия бирү (госел коену, хәез (менструация), нифас (бала тапканнан соң кан килү) мәсьәләләре һ. б.).

Болар арасында иң мөһиме - әлбәттә, иман тәрбиясе бирү. Баланың инануы ислам диненә генә бәйле булырга тиеш. Иман тәрбиясе алганнан соң исламны гына дин, Коръәнне генә әйдәүчесе, Пәйгамбәребезне (сгв) генә мисал һәм үрнәк итеп белергә тиеш.

Хайван да баласын бәләкәйдән өйрәтә: нәрсәдән куркырга, нәрсә ашарга-ашамаска. Адәм баласы тәрбия алырга хаклырак түгелмени?

**Рафикъ хәзрәт МИҢНӘХМӘТОВ,**
**Татарстанның көнчыгыш төбәге казые,**
**Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең Голамәләр шурасы әгъзасы,**
**Әлмәт районы имам-мөхтәсибе**

**«Дин вә мәгыйшәт» газетасы. № 6 (175) чыгарылыш.**
**Гамәлгә куючы һәм нәшир:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте.
**Баш мөхәррир:** Ришат ХӘМИДУЛЛИН.
**Мөхәррир:** Нияз САБИРҖАНОВ.
**Дизайнер:** Рөстәм МИҢНУЛЛИН.
**Тираж:** 5000 данә. **Заказ:** № 35389.

**Газетаны ваклап сатуда тәкъдим ителгән бәя - 3,00 сум.**
**Редакция һәм нәшер итүче адресы:** 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27. "Дин вә мәгыйшәт" газетасы редакциясе. Язылу индексы - 16046.
***График буенча бу санга 7 февраль көнне 17.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды – 17.00 сәгатьтә.***
*Теркәлү турында таныклык: Татарстан матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 февралендә 240 нчы номер белән теркәлде.*
**Электрон адрес:** niyaz.kazan@yandex.ru **Тел.:** 8(843)267-29-67.

Газета "Татмедиа" ААҖ филиалы – "Идел-Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2).

**Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръәннән аятьләр бар, тиешсез урынга кулланудан сакланыгыз!**